| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕАКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР АКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

Зур Аксу ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 декабрь 2023 ел № 10

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1978 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәнең I бүлегенә кертелергә Республики Татарстан от 22.09.2023 № 6, түбәндәге үзгәрешләр:

1) 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнарның яшәү урыны яки булган урыны (3 айдан артык срокка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) булган урыны, яки альтернатив гражданлык хезмәте үткән урыны, яки җәзаны үтәгән урыны буенча теркәлмәгән гражданнарның шәхси хәрби исәп - хисабы муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатлары (алга таба-хәрби комиссариатлар) тарафыннан башкарыла.»;

2) 8 нче пунктта:

а) а пунктчасында 27 ел сүзләрен 30 ел сүзләре белән алыштырырга;

б) б пунктчасының 7-9 абзацларында 27 ел сүзләрен 30 ел сүзләре белән алыштырырга.

3) 9 нчы пунктның «в» пунктчасын алып ташларга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Зур Аксу авыл
җирлеге Башлыгы: С.П.Унисков